Җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына аукцион үткәрү турында белдерү

2021 елның 11 маендагы 157-з номерлы, 158-з номерлы күрсәтмәләр нигезендә Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (вәкаләтле орган һәм аукционны оештыручы) түбәндәге җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына ачык аукцион үткәрү турында хәбәр итә:

| Лот № ы | Җир кишәрлегенең урнашкан урыны, кадастр номеры | Кадастр номеры | Җир кишәрлеге милекчесе | Мәйданы, кв. м. | Җирләрнең категориясе | Рөхсәт ителгән куллану | Чикләүләр һәм йөкләмәләр турында мәгълүмат | Аренда вакыты | Еллык аренда түләвенең башлангыч күләме, сум. | Аукцион адымы, сум. | Задаток, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Зур Кукмара авылы, Сара Садыйкова ур., 41 * | 16:23:071002:577 | чикләнмәгән җирләр | 1200 | торак пунктлар җирләре | шәхси торак төзелеше өчен | РФ Җир кодексының 56, 56.1 статьяларында каралган җир кишәрлегенә хокукларны чикләү | 20 | 15111 | 453 | 3022 |
| 2 | Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Зур Кукмара авылы, Каюм Насыйри ур., з/у 5 * | 16:23:071001:666 | чикләнмәгән җирләр | 1275 | торак пунктлар җирләре | шәхси торак төзелеше өчен | ЕГРН нан алынган өземтәдә мәгълүматлар юк | 20 | 16055,44 | 482 | 3211 |

Аукцион 2021 елның 06 августында 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча узачак: Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ленин ур., 15 йорт, 1 кат, 101 бүлмә.

Аукционда катнашу өчен гаризалар эш көннәрендә 2021 елның 01июленнән 2021 елның 02 августына кадәр 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр, 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке ашка тәнәфес белән, ТР, Кукмара ш., Ленин ур., 15 йорт, 1 кат, 101 бүлмә адресында кабул ителә. Белешмә өчен телефон: 8(84364) 2-61-56. Элемтә өчен җаваплы зат –Насыйбуллина Эльвира Фирдәүс кызы.

Аукционда катнашу өчен гариза билгеләнгән формада, задатокны кире кайтару өчен счет реквизитларын күрсәтеп, ике нөсхәдә төзелә. Гаризага кушымта итеп бирелә: гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документлар күчермәләре (гражданнар өчен), задаток кертүне раслый торган документлар. Задаток кертүне раслый торган документларны тапшыру задаток турында килешү төзү дип танылa. Тапшырыла торган документларның барлык битләре, шул исәптән гариза да, тегелергә, номерланырга, гариза бирүче яисә гариза бирүченең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланырга һәм гариза бирүченең мөһере белән беркетелергә тиеш. Гаризаны дәгъвачы вәкиле биргән очракта тиешенчә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе тапшырыла.

1 нче, 2 нче лот буенча аукцион РФ Җир Кодексының 39.18 статьясының 7 пунктында каралган очрак буенча үткәрелә, анда гражданнар гына катнаша ала.

Гариза бирүчегә түбәндәге нигезләр буенча аукционда катнашырга рөхсәт ителми:

1) аукционда катнашу өчен кирәкле документларны тапшырмау яки дөрес булмаган белешмәләр бирү;

2) аукционда катнашу өчен гаризаларны карау датасына задатокның бирелмәве;

3) аукционда катнашу өчен гаризаның Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә конкрет аукционда катнашучы, конкрет җир кишәрлеген арендалаучы булырга хокуклы булмаган зат тарафыннан бирелүе;

4) гариза бирүче турында, гамәлгә куючылар (катнашучылар) турында, гариза бирүченең коллегиаль башкарма органнары әгъзалары турында, гариза бирүченең юридик зат булган ялгыз башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар турында белешмәләрнең аукционның намуссыз катнашучылары реестрында булуы.

Задаток кертү өчен хисап реквизитлары:

Алучысы: Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (ЛР236060442-ИМУЩ), ИНН 1623008271, КПП 162301001

Алучы банкы: РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕГЕ/ Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Казан шәһәре, БИК 019205400

Алучы банкы хисабы: 40102810445370000079, акчаларны алучы хисабы: 03232643926330001100

Түләүнең билгелнеше: 2021 елның 06 августында аукционда катнашу өчен задаток кертү.

Гаризалар кабул итү вакыты чыкканнан соң кергән аукционда катнашу өчен гариза гариза бирүчегә кергән көнендә кире кайтарыла.

Гариза бирүче аукционны оештыручы тарафыннан кабул ителгән аукционда катнашуга гаризасын, гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланганчыга кадәр аукционны оештыручыга язмача хәбәр итеп кире алырга хокуклы. Аукционны оештыручы гариза бирүчегә ул керткән задатокны гаризаны кире алу турында хәбәрнамә кергән көннән алып өч эш көне эчендә кире кайтара. Гариза бирүче гаризасын гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң кире алган очракта задаток аукционда катнашучылар өчен билгеләнгән тәртиптә кире кайтарыла. Аукционны оештыручы, гаризалар кабул итүнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча, аукцион үткәрүдән баш тартырга хокуклы.

Гаризаларны карау 2021 елның 05 августында 14.00 сәгатьтә Кукмара ш., Ленин ур., 15, 1 кат, 101 бүлмәдә булачак. Аукционда катнашучылар дип танылган яки аукционда катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләргә, аукционда катнашу өчен гаризалар каралганнан соң икенче көннән дә соңга калмыйча, кабул ителгән карар турында хәбәр ителә. Аукционда катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләргә задаток гаризаларны карау беркетмәсен рәсмиләштергәннән соң өч эш көне эчендә кире кайтарыла.

Аукционның җиңүчесе дип җир кишәрлеге өчен иң зур күләмдә еллык аренда түләве тәкъдим иткән аукционда катнашучы танылa. Аукцион үткәрү көнендә Кукмара ш., Ленин ур., 15 й., 1 кат, 101 бүлмәдә аукцион нәтиҗәләре турында ике нөсхәдә беркетмә төзелә, аларның берсе аукцион җиңүчесенә тапшырыла, ә икенчесе аукционны оештыручыда кала. Аренда килешүе төзелә торган зат тарафыннан кертелгән задаток аның өчен аренда түләве хисабына исәпләнә. Аукционда катнашкан, әмма анда җиңмәгән затларга задатоклар аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә кул куелганнан соң өч эш көне эчендә кире кайтарыла.

Аукцион түбәндәге очракларда тормышка ашмаган дип танылa:

а) Әгәр аукционда катнашуга гаризаларны карау нәтиҗәләре нигезендә барлык гариза бирүчеләрне аукционда катнашуга кертүдән баш тарту турында һәм аукционда катнашучы итеп бер генә гариза бирүчене тану турында карар кабул ителгән булса;

б) Әгәр аукционда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң, аукционда катнашуга бары тик бер генә гариза бирелгән яки аукционда катнашуга бер генә гариза да бирелмәгән булса.

Югарыда санап үтелгән очракларда, гариза бирүченең һәм аның аукционда катнашуга бирелгән гаризасының аукцион шартларында билгеләнгән таләпләргә һәм аукцион шартларына туры килгән шартта, вәкаләтле орган аукционда катнашу өчен гаризаларны карау беркетмәсенә кул куйганнан соң ун көн эчендә гариза бирүчегә имзаланган җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проектының өч нөсхәсен җибәрә. Шул ук вакытта аренда килешүе аукцион предметының башлангыч бәясе буенча төзелә.

в) Әгәр аукционда бары тик бер катнашучы гына булса яки аукцион үткәргәндә аукционда катнашучыларның берсе дә катнашмаган булса, яки, аукцион предметының башлангыч бәясе турында өч тапкыр тәкъдим белдерелгәннән соң, аукцион предметының бәясе турында аукцион предметының югарырак бәясен күздә тоткан бер генә тәкъдим дә кертелмәгән булса. Бу очракта вәкаләтле орган аукцион җиңүчесенә яки аукционда катнашкан бердәнбер катнашучыга аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә төзелгән көннән соң ун көн эчендә өч нөсхәдә аренда шартнамәсенең имзаланган проектын җибәрә. Бу вакытта җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе аукцион җиңүчесе тәкъдим иткән бәядән яисә күрсәтелгән килешү аукционда катнашкан бердәнбер катнашучы белән төзелгән очракта - аукцион предметының башлангыч бәясе буенча төзелә.

Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүматны торгларның рәсми сайтында урнаштырганнан соң кимендә ун көннән соң төзелә.

Әгәр аукционда җиңүчегә (бердәнбер гариза бирүчегә, аукционның бердәнбер катнашучысына) җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты җибәрелгәннән соң утыз көн эчендә күрсәтелгән шартнамәгә аның тарафыннан кул куелмаса һәм вәкаләтле органга тапшырылмаса, задаток мондый затка кире кайтарылмый.

Әгәр җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе аукционда җиңүчегә күрсәтелгән шартнамә проекты җибәрелгән көннән алып утыз көн эчендә имзаланмаган һәм вәкаләтле органга тапшырылмаган булса, аукционны оештыручы аукцион предметының бәясе турында соңгыдан алдагы тәкъдимне ясаган аукционда катнашучыга аукцион җиңүчесе тәкъдим иткән бәя буенча аренда шартнамәсе төзергә тәкъдим итә. Аукцион предметының бәясе турында соңгыдан алдагы тәкъдимне ясаган аукцион катнашучысына җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты җибәрелгән көннән соң утыз көн эчендә бу катнашучы вәкаләтле органга кул куелган шартнамәне тапшырмаса, аукционны оештыручы кабат аукцион үткәрү турында игълан итәргә яки җир кишәрлеге белән Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә бүтәнчә эш итәргә хокуклы.

Тулырак мәгълүмат алырга, гариза формасы, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты белән гаризаларны кабул итү урынында һәм «www.torgi.gov.ru», «www.kukmor.tatarstan.ru. сайтларында танышырга мөмкин.

ЕГРН нан өземтәдә җир кишәрлегенең урнашу урыны тасвирламасы нигезендә җир кишәрлеге чикләре

Урында җир кишәрлеген карау гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә теләсә кайсы вакытта башкарыла.

* Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә җир кишәрлеге Ж-1 зонасында урнашкан. «Шәхси торак йортлар төзү зонасы». Ж-1 шәхси торак йортлар төзү зонасы йорт яны җир кишәрлекләре булган һәм/яки алардан башка аерым тора торган һәм блокланган шәхси торак йортлардан (коттеджлардан) җирле әһәмияттәге хезмәтләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасы белән торак районнарын формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән.

Күчемсез милекне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

– Шәхси торак йортлар;
– Блокланган торак йортлар.

Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре:

- аерым тора торган яки торак йортларга тоташтырып төзелгән гаражлар яки ачык автомобиль кую урыны: шәхси кишәрлеккә 2 машина урыны;
- хуҗалык, ишегалды корылмалары;җиләк-җимеш, яшелчә бакчалары, йорт каршындагы бакчалар;теплицалар, оранжереялар;
- гомуми мәйданы 150 кв. метрдан артмаган беренче кирәкле товарлар кибетләре.
- даруханәләр;гомуми мәйданы 600 кв. метрдан артмаган амбулатор-поликлиника учреждениеләре;
- су саклау өчен шәхси резервуарлар;су җыю өчен скважиналар, шәхси коелар (җир асты суларының якланганлык дәрәҗәсенә карап, кимендә 30 м һәм 50 м арада санитар саклау зонасын оештыру шарты белән);
- шәхси бассейннар;
- шәхси мунчалар, сауналар, ишегалды бәдрәфләре;
- янгыннан саклау объектлары (гидрантлар, резервуарлар, янгынга каршы сулыклар);
- ашламалар саклау өчен мәйданчыклар, компост мәйданчыклары, чокырлар һәм тартмалар;
- чүп җыю өчен мәйданчыклар.

Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләре:

- фатир яны кишәрлекләре булган яки алардан башка, биеклеге 4 каттан да артмаган аз катлы күпфатирлы торак йортлар;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр;
- кер юу һәм химик чистартуга кабул итү пунктлары;
- күп дигәндә 20 урынлы кунакханәләр;
- вакытлы сәүдә объектлары;
- офислар, банк бүлекләре;клублар (мәдәният йортлары);
- китапханәләр;гыйбадәт объектлары;фельдшер-акушерлык пунктлары;
- йорт хайваннарын һәм кош-кортны тоту өчен төзелмәләр (дустанә күршелек мөнәсәбәтләрен үтәү шарты белән);
- малларны даими асрамый торган ветеринария шифаханәсе.
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;
- спорт заллары, рекреация заллары;
- күп максатлы һәм махсуслаштырылган билгеләнешле клублар (эш вакыты буенча чикләнгән);
- полиция бүлекләре, участок пунктлары;
- элемтә бүлекләре;
- торак-эксплуатация һәм авария-диспетчерлык хезмәтләре;
- хезмәт күрсәтүче һәм коммерция кулланылышы төрендәге объектлар каршындагы парковкалар;
- кәрәзле, радиореле, спутник элемтәсе антенналары;
- кабул итү пунктлары һәм вак-төяк көнкүреш әйберләрен ремонтлау (аяк киеме, кием, кулчатыр, сәгать ремонтлау һ. б.) буенча остаханәләр;
- 100 кв. м га кадәр мәйданлы тегү ательесы һәм остаханәләр;
- чәчтарашханәләр, косметика салоннары, матурлык салоннары;

- һәйкәлләр һәм истәлекле билгеләр.